| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 27 ноябре Олы Ачасыр авылы № 31

Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 1 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итте:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторларының бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 1 сентябрендәге 21 номерлы карары белән расланган карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «б» пунктчасының алтынчы абзацында «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү гамәлгә ашырылган көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә.

1.2. 5 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү;

бюджетка түләүләр, алар буенча пенялар һәм штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе Финанс

министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән регламентын билгеләү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл
жирлеге башлыгы И.М. Саттаров